ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ
**КАРАРЫ**

Алтынчы чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советының дүртенче утырышы көн тәртибе турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы КАРАР БИРӘ:

Алтынчы чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советы дүртенче утырышының түбәндәге көн тәртибен расларга:

1. Татарстан Республикасы җәмәгать судьяларын сайлау турында.
2. Татарстан Республикасы җәмәгать судьясы вазыйфаларын башкару турында.
3. «2020 елга, 2021 һәм 2022 еллар план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында» 5-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында (I укылыш).
4. «2020 елга, 2021 һәм 2022 еллар план чорына Татарстан Республикасы Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды бюджеты турында» 6-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында (I укылыш).
5. «Татарстан Республикасында мәдәни мирас объектлары турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 601-5 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (II укылыш).
6. «Татарстан Республикасы дәүләт мөлкәтен хосусыйлаштыру турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 4-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).
7. «Татарстан Республикасында кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү турында» Татарстан Республикасы Законының 6 һәм 8 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» 3-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).
8. «Татарстан Республикасында шәһәр төзелеше эшчәнлеге турында» Татарстан Республикасы Законының $2^1$ һәм 18 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» 7-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).

9. «Татарстан Республикасы Экология кодексына үзгәрешләр кертү турында» 8-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында (I укылыш).

10. «Муниципаль районнарның һәм шәһәр округларының җирле үзидарә органнарына хайваннар чирләрен кисәтү һәм бетерү, аларны дәвалау, хуҗасыз йорт хайваннарын аулау һәм асрау, кеше һәм хайваннар өчен уртак чирләрдән халыкны яклау чараларын үткәрүне оештыру өлкәсендә Татарстан Республикасының аерым дәүләт вәкаләтләрен бирү турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 11-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).

11. «Наркоманияне һәм токсикоманияне профилактикалау турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 9-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш)

12. «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 10 һәм 112 статьяларына һәм «Татарстан Республикасы җәмәгать судьялары турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 10-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).

13. «Татарстан Республикасы Дәүләт Советы комитетларын төзү турында» 2019 елның 20 сентябрендәге 12-VI ДС номерлы Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карарына үзгәрешләр кертү хакында.

14. «Ватаным Татарстан» һәм «Республика Татарстан» газеталарының эшчәнлеген камилләштерү һәм эш нәтиҗәлелеген арттыру турында» 2009 елның 22 апрелендәге 94-IV ДС номерлы Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карарына үзгәреш кертү хакында.

15. «Аерым федераль законнарга үзгәрешләр кертү турында» 754238-7 номерлы федераль закон проекты хакында (федераль законнарның фактта үз көчләрен югалткан нигезләмәләрен төшереп калдыру өлешендә).

16. «Россия Федерациясе Торак кодексының 193 статьясына үзгәреш кертү турында» 746597-7 номерлы федераль закон проекты хакында (лицензия таләпләре исемлеген тулыландыру өлешендә).

17. «Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 742962-7 номерлы федераль закон проекты хакында (торак фондына реновация уздырганда мөнәсәбәтләрне җайга салу өлешендә).

18. «Россия Федерациясе Салым кодексына үзгәрешләр кертү турында (федераль бюджетка күчерелә торган табышка салымның арттырылган ставкасын куллану чорын үзгәртү өлешендә)» 798485-7 номерлы федераль закон проекты хакында.

19. «Россия Федерациясе Бюджет кодексының $47^2$ статьясына үзгәрешләр кертү турында» 804315-7 номерлы федераль закон проекты хакында (бюджет керемнәре администраторларының бюджетка түләүләр буенча бурычны

кайтаруның өметсезлеген тану турында карарлар кабул итүгә бәйле бюджет вәкаләтләрен үтәвен камилләштерү өлешендә).

20. «Террорчылыкка каршы тору турында» Федераль законның 21 статьясына үзгәреш кертү хакында» 803209-7 номерлы федераль закон проекты турында (бер мәртәбә бирелә торган пособиеләрне түләү тәртибен төгәлләштерү өлешендә).

21. «Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексына үзгәрешләр кертү хакында» 796986-7 номерлы федераль закон проекты турында (белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы оешмаларның һәм аларның вазыйфаи затларының чит тел буларак рус теле, Россия тарихы һәм Россия Федерациясе законнары нигезләре буенча имтихан үткәрү таләпләрен, шулай ук тиешле федераль мәгълүмат системасына күрсәтелгән фәннәр буенча кирәкле белемнәрнең булуын раслый торган документлар хакында белешмәләр кертү тәртибен бозган өчен җаваплылыгын билгеләү өлешендә).

22. «Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексына үзгәрешләр кертү хакында» 792106-7 номерлы федераль закон проекты турында (маршрутның картасы булмыйча, даими рәвештә пассажирлар йөртү өчен автобустан, трамвайдан яисә троллейбустан яңадан файдаланган өчен административ җаваплылык билгеләү өлешендә).

23. «Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексына үзгәрешләр кертү хакында» 796001-7 номерлы федераль закон проекты турында (Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексының 15.5 статьясында каралган административ хокук бозулар хакындагы эшләрне җәмәгать судьяларының суд карамагыннан төшереп калдыру һәм шушы категориядәге эшләрне салым органнары каравына тапшыру максатларында).

24. Хөкүмәт сәгате: «Татарстан Республикасында җитештерү һәм куллану калдыклары белән эш итүнең яңа системасына күчү проблемалары турында».

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе — Ф.Х. Мөхәммәтшин

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ АППАРАТЫ
АППАРАТ ГОСУДАРСТВЕННОГО СОВЕТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
БЕРКЕТМӘ БҮЛЕГЕ
ПРОТОКОЛЬНЫЙ ОТДЕЛ

Казан шәһәре,
2019 елның 23 октябре
№ 99-VI ДС